Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Советының икенче утырышы

Богородский авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

12 ноябрь, 2020 ел № 8

Богородский авыл җирлеге территориясендә гражданнар җыелышларын һәм конференцияләрен билгеләү һәм үткәрү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Богородский авыл җирлеге Советының 2008 елның 14 декабрендәге 19 номерлы карары белән расланган Богородский авыл җирлеге территориясендә гражданнарның җыелышларын һәм конференцияләрен билгеләү һәм үткәрү тәртибен туры китерү максатларында **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлеге Советы карар чыгарды:**

1. Богородский авыл җирлеге Советы карары белән расланган Богородский авыл җирлеге территориясендә гражданнарның җыелышларын һәм конференцияләрен билгеләү һәм үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешнең 1.2 пунктчасында «һәм Богородский авыл җирлеге җирле үзидарәсенең вазыйфаи затлары,» сүзләреннән соң «инициатив проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча фикер алышу.» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Богородский авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башлыгы М.Н. Бикбов